**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«__21___» ____03____ 2019 ел** **№ __64____**

2019 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатыннан гражданнарның һәм алар белән берлектә даими яшәүче аларның гаилә әгъзаларының максималь керем күләмен һәм аларның мөлкәтләренә салым салынырга тиешле хакын билгеләү турында

РФ Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Азнакай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында» гы 23.019 номерлы карары нигезендә, **карар чыгарам:**

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме тәшкил итә:

1.1.1 Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 523 610 сум;
1.1.2.Ике кешедән торган гайлә өчен – 1 939 140 сум;
1.1.3.Өч кешедән торган гайлә өчен – 2 493 180 сум;
1.1.4 Дүрт кешедән торган гайлә өчен – 3 324 240 сум;;
1.1.5.Биш кешедән торган гайлә өчен – 4 155 300 сум;;
1.1.6.Алты кешедән торган гайлә өчен – 4 986 360 сум;
1.1.7.Җиде кешедән торган гайлә өчен – 5 817 420 сум;;
1.1.8.Сигез кешедән торган гайлә өчен – 6 648 480 сум;
1.1.9.Тугыз кешедән торган гайлә өчен – 7 479 540 сум;
1.1.10.Ун кешедән торган гайлә өчен – 8 310 600 сум;

1.2.1 Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь къръсщткече:

1.2.2 Ялгыз яшәүче граждан өчен –19781,39 рублей;

1.2.3 Ике кешедән торган гайлә өчен –12588,16 рублей;

1.2.4 Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гайлә өчен –10789,85 рублей.

2. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге әлеге карар имзаланганнан соң 10 көн эчендә әлеге карарны рәсми басма – «Маяк» газетасында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов